КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 апрель г.Казань № 545

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алу аркасында гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан күрелгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алу аркасында гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан күрелгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче; 2021 ел, 18 июнь, 478 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибен раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алу кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның

аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алу аркасында гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан күрелгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен (карарга теркәлә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 14 февраль, 84 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 апрель, 545 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында күрелгән зыянны хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына (алга таба – алучы) каплау (алга таба – зыянны каплау) механизмын билгели.

2. Зыянны каплау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Алучыда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 26 май, 310 нчы карары белән расланган Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу кагыйдәләренең кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу турында акт (алга таба – хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу турында акт) һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алуны оештыру һәм үткәрү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары булу зыянны каплау өчен нигез булып тора.

3. Зыянны каплау күләме хайваннарга һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукциягә куелган, дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр нигезендә, әгәр мондый бәяләр билгеләнгән булса, ә калган очракларда алынган хайваннарның һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукциянең базар кыйммәте нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә. Зыянны каплау күләме хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерү

шартнамәсе буенча алучыга башкарылган иминият түләүләре суммасын тотып калып билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен каплау күләме киметелергә яки «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясы нигезендә хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен каплаудан баш тартылырга мөмкин.

5. Зыянны каплау максаты белән алучы хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция алынып беткән көннән 60 календарь көн эчендә вәкаләтле органга әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча зыянны каплау турында гариза (алга таба – гариза) бирә, аңа түбәндәге документлар теркәлә:

шәхесне таныклый торган документ күчермәсе (граждан өчен), йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе (юридик зат өчен), йә Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсе (индивидуаль эшмәкәрләр өчен);

хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу турында акт;

хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерү шартнамәсе күчермәсе (хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерүне раслый торган башка документ) яки алучының хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерү шартнамәсе булмавын раслый торган гарантия хаты;

хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерү шартнамәсе буенча башкарылган иминият түләүләре турында белешмә;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язма ризалык (шәхси эшмәкәрләр, физик затлар өчен).

6. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гаризаны кергән көнендә терки.

Алучы тарафыннан документларның тулы исемлеге тапшырылмаган һәм (яки) әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларда дөрес булмаган мәгълүмат чагылдырылган очракта, вәкаләтле орган, әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәлгән көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча, аны алучыга, кире кайтару сәбәбен күрсәтеп, язма хәбәрнамә белән кире кайтара.

Алучы, әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гаризаны кире кайтару сәбәпләре бетерелгәннән соң, вәкаләтле органга  гариза белән, әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7. Алучы үзе тапшыра торган әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

Алучы, зыянны каплаганда хокуклары бозылган очракта, вәкаләтле органның гамәлләренә карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

8. Вәкаләтле органның җитәкчесе әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кергән көннән ике эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция өчен акча алучылар реестрын (алга таба – Реестр) формалаштыра һәм Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең территориаль органына (алга таба – территориаль орган) түбәндәгеләрдә каралган очракларның булуы яки булмавы турында рәсми сорау җибәрә:

хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан эшләнгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау күләме киметелә алган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау күләме киметелә алган очраклар исемлеген һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплауда баш тартыла алган очраклар исемлеген раслау турында» 2023 ел, 1 февраль, 139 нчы карары белән расланган очраклар исемлегендә (алга таба – зыянны каплау күләмен киметү очраклары исемлеге);

хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплаудан баш тартыла алган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау күләме киметелә алган очраклар исемлеген һәм хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплауда баш тартыла алган очраклар исемлеген раслау турында» 2023 ел, 1 февраль, 139 нчы карары белән расланган очраклар исемлегендә (алга таба – зыянны каплауда баш тартыла алган очраклар исемлеге).

9. Территориаль органнан зыянны каплау күләмен киметү очраклары исемлегендә һәм зыянны каплауда баш тартыла алган очраклар исемлегендә каралган очраклар булмау турында мәгълүмат алганда вәкаләтле органның җитәкчесе әлеге мәгълүматны алган көннән биш эш көне эчендә зыянны каплау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – зыянны каплау турында карар) проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга җибәрә.

10. Территориаль органнан зыянны каплау күләмен киметү очраклары исемлегенә кертелгән очраклар булу турында мәгълүмат алганда вәкаләтле органның җитәкчесе әлеге мәгълүматны алган көннән биш эш көне эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау күләмен киметү кагыйдәләрен раслау турында» 2023 ел, 1 февралендәге 140 номерлы карары белән расланган Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау күләмен киметү кагыйдәләренең 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән зыянны каплау күләмен киметү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – зыянны каплау күләмен киметү турында карар) проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга җибәрә.

11. Территориаль органнан зыянны каплаудан баш тартыла алган очраклар исемлегенә кертелгән очраклар булу турында мәгълүмат алганда вәкаләтле орган әлеге мәгълүматны алган көннән биш эш көне эчендә зыянны каплаудан баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – зыянны каплаудан баш тарту турында карар) проектын эшли һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга җибәрә.

12. Вәкаләтле органнан зыянны каплау турында, зыянны каплау күләмен киметү турында яки зыянны каплаудан баш тарту турында карар проектын алган көннән биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шул ук эзлеклелектә зыянны каплау турында, зыянны каплау күләмен киметү турында яки зыянны каплаудан баш тарту турында карар кабул итә.

Кабул ителгән карарның нигезләве белән зыянны каплау турында, зыянны каплау күләмен киметү турында яки зыянны каплаудан баш тарту турындагы карар алучыга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан зыянны каплау турында карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелә.

Зыянны каплау турындагы яки зыянны каплау күләмен киметү турындагы карарда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән зыянны каплау чыганагы, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан вәкаләтле органга иң күбе 90 эш көненнән торган зыянны каплауны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын ирештерү срогы билгеләнә.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бер эш көне эчендә зыянны каплау турында йә зыянны каплау күләмен киметү турындагы карарны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм вәкаләтле органга җибәрә.

14. Вәкаләтле орган, аңа зыянны каплауга бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән соң, биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән

продукция алынган муниципаль берәмлектә урнашкан вәкаләтле органның ведомство буйсынуындагы дәүләт ветеринария оешмасына (алга таба – ведомство буйсынуындагы оешма) ачылган шәхси счетка зыянны каплауга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә акча күчерүне гамәлгә ашыра.

Ведомство буйсынуындагы оешма үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына зыянны каплауга акча кергәннән соң биш эш көне эчендә аларны алучыларның кредит оешмаларында ачылган счетларына алучының зыянны каплауга акча алу хокукын раслый торган документлар нигезендә күчерүне гамәлгә ашыра.

11. Алучы тарафыннан зыянны каплауга акча алу өчен дөрес булмаган документлар бирелү фактлары ачыкланганнан соң вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә алучы тарафыннан зыянны каплауга алынган акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

12. Зыянны каплау өчен бирелә торган акча әлеге Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән срокта Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, әлеге акча вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның
аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү
максатлары өчен хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән
продукцияне алу аркасында хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән
продукция хуҗасы тарафыннан күрелгән зыянны каплау турында
гариза

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Физик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда), паспорт мәгълүматлары, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) / юридик затның тулы исеме, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН), төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) | |
| 2. | Физик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны / юридик затның урнашу урыны | |
| 3. | Кредит оешмасы исемен күрсәтеп, кредит оешмасында ачылган шәхси (исәп-хисап) счеты номеры | |
| 4. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу турында карары датасы һәм номеры | |
| 5. | Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алу турында акт датасы | |
| 6. | Хайваннар төре һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция исеме | |
| 7. | Саны, авырлыгы, үлчәү берәмлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Зыянны каплау мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын алу өчен уңайлы ысул | e-mail: ______________________________<br>почта адресы: ____________________<br>____________________________________<br>башка вариант:<br>______________________ |

___________________ ___________________________________________________________

(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

_______________________

(дата, ай, ел)

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә утильләштерү максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## Алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция өчен акча алучылар реестры

| Т/с | Физик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), паспорт мәгълүматлары, салым түләүченең тәнгәлләштерү номеры (ИНН) / юридик затның тулы исеме, салым түләүченең тәнгәлләштерү номеры (ИНН), төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) | Физик затның яшәү урыны / юридик затның урнашу урыны | Кредит оешмасы исемен күрсәтеп, кредит оешмасында ачылган шәхси (исәп-хисап) счеты номеры | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алуны оештыру һәм үткәрү турында карары датасы һәм номеры | Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне алуны оештыру һәм үткәрү турында акт датасы | Хайваннар төре һәм (яки) хайваннар-дан җитеште-релгән продукция исеме | Саны, авыр-лыгы, үлчәү берәм-леге | Алынган хайванның / хайваннардан җитештерел-гән һәм алын-ган продук-циянең кыйм-мәте, бер берәмлек, сум | Хайваннарны һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукцияне иминләштерү шартнамәсе буенча физик затка яки юридик затка башкарылган иминият түләүләре суммасы, сум | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә зыянны каплау проценты (100 процент, 50 процент, 25 процент) | Зыянны каплау суммасы – барлыгы, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы

_________ ______________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсенә караган бухгалтерлык исәбе, хисаплылык, икътисадны планлаштыру бүлеге башлыгы

_________ ______________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

______________________________